| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ЗАКУПКАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ САТЫП АЛУЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**10.09.2024** **№ 04-05-96**

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы Сатып алулар буенча дәүләт комитетының 2023 елның 10 ноябрендә 04-05-105 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Сатып алулар буенча дәүләт комитетының Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Сатып алулар буенча дәүләт комитеты тарафаннан идарә ителә торган түләүләр буенча бурычларны түләттерү өметсез дип тану турында карарны кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Сатып алулар буенча дәүләт комитетының 2023 елның 10 ноябрендә 04-05-105 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Сатып алулар буенча дәүләт комитетының Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Сатып алулар буенча дәүләт комитеты тарафаннан идарә ителә торган түләүләр буенча бурычларны түләттерү өметсез дип тану турында карарны кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертертергә:

2 пунктта:

2.2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. «Бөлгенлек (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-

ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданинның, шәхси эшмәкәрнең банкротлык процедурасын тәмамлау – күрсәтелгән Федераль закон нигезендә аны түләү йөкләмәсен үтәүдән ул азат ителгән бюджетка түләүләр буенча бурыч өлешендә;»;

2.3 пунктчасы үз көчен югалткан дип таныырга;

2.5 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Штраф рәвешендә хөкем ителгәннәргә карата амнистия яки ярлыкау турында актлар куллану яки суд тарафыннан карар кабул итү, аңа ярашлы рәвештә Дәүләт комитеты бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләттерү мөмкинлеген югалта, шул исәптән аны түләттерүнең билгеләнгән срогы узуга бәйле рәвештә;»;

2.6 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6. Башкару эше турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яисә 4 пунктында каралган нигез буенча башкару документын түләтүчегә кире кайтарганда, әгәр бурычлыга карата банкротлык турындагы эш буенча производство ачу өчен бөлгенлек (банкротлык) турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләр күләменнән артмаган бурыч барлыкка килгән көннән биш елдан артык вакыт узган булса, башкаручы суд приставы тарафыннан башкару эшен тәмамлау турында карар чыгару;»;

түбәндәге эчтәлекле 2.6[1] пунктча өстәргә:

«2.6[1] Банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек акчалар булмау сәбәпле бурычлыны банкрот дип тану яисә банкротлык турындагы эш буенча эшне туктату турындагы гаризаны кире кайтару турындагы актны суд тарафыннан кабул итү;»;

2.7 пунктчага түбәндәге эчтәлекле җөмләне өстәргә:

«Юридик затларны һәм шәхси эшмәкәрләрне дәүләт теркәвенә алу турында» 2001 елның 8 августындагы 129-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә теркәүгә ала торган органның юридик затны Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру турындагы карары гамәлдә түгел дип танылган очракта, әлеге пунктча нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча элегрәк түләттерү өчен өметсез дип танылган бурычы бюджет (бухгалтерия) исәбендә торгызылырга тиеш.»;

4 пунктның 4.3 пунктчасында:

дүртенче абзацта «2.3 пунктчасында» сүзләрен «2.2 пунктчасында» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «2.6 пунктчасында» сүзләрен «2.6, 2.6[1] пунктчаларында» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацта «2.6 пунктчасының өченче абзацында» сүзләрен «2.6[1] пунктчасында» сүләренә алмаштырырга;

10 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Комиссия Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләттерү өметсез дип тану турындагы мәсьәләне тәкъдим ителгән документлар нигезендә алар Комиссиягә кергән көннән алып унбиш эш көне эчендә карый. Камиссия утырышында Комиссия әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, аның карары тулы хокуклы була. Комиссия карары ачык тавыш бирү юлы белән утырышта катнашучы Комиссия әгъзаларының гомуми саныннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар саны тигез булган очракта Комиссия утырышында председательлек итүченең тавышы хәлиткеч булып санала.»;

11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Комиссия утырышы йомгаклары буенча Тәртипнең 10 пунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән очракта, утырыш уздырылган көннән алып биш эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләттерү өметсез дип тану турында карар проекты әзерләнә.

Комиссия карары Комиссия утырышы уздырылган көннән алып биш эш көне эчендә түбәндәге мәгълүматны үз эченә алган акт белән рәсмиләштерелә:

оешманың тулы исеме (физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (соңгысы – булган очракта));

салым түләүченең идентификация номеры, төп дәүләт теркәү номеры, оешма салым түләүченең исәпкә кую сәбәбе коды (физик зат салым түләүченең идентификация номеры (булган очракта));

бурыч барлыкка килгән Татарстан Республикасы бюджетына түләү турында мәгълүматлар;

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурыч исәпкә алына торган Татарстан Республикасы бюджетлары керемнәрен классификацияләү коды, аның исеме;

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурыч суммасы;

Татарстан Республикасы бюджетына тиешле түләүләр буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурыч суммасы;

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләттерү өметсез дип тану турында карар кабул ителгән көн.

Акт ике данәдә төзелә һәм утырышта председательлек итүче һәм утырышта катнашкан Комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана.

Комиссия тарафыннан төзелгән акт имзаланган көннән алып биш эш көне эчендә Дәүләт комитеты рәисе тарафыннан раслана.»;

түбәндәге эчтәлекле 12 пунктны өстәргә:

«12. Тәртипнең 10 пунктындагы дүртенче абзацында күрсәтелгән очракта Комиссия утырышы беркетмәсендә Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләттерү өметсез дип тану өчен нигезләр булмау турындагы мәгълүмат чагылдырыла. Беркетмә утырышта председательлек итүче һәм Комиссия секретаре тарафыннан имзалана һәм Дәүләт комитеты рәисенә (аның вазыйфаларын башкаручы затка) хәбәр итү өчен җибәрелә.».

Рәис М.Г.Зиатдинов